Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Ширәмәт авыл җирлеге составына керүче Поповка пунктында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2021 елның 17 ноябре

№ 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Ширәмәт авыл җирлегенең Поповка пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Түбән Кама муниципаль районының Ширәмәт авыл җирлеге Поповка пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә 2022 елда үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны Солнечная урамында балалар мәйданчыгы төзүгә (төзелеш материаллары сатып алуга, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә) юнәлдерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Ширәмәт авыл җирлеге башлыгы

В.И. Никишин